Еллар узган саен авылларыбыз матурая, kvз алда vзгәрә.
Ләмберә турында да шундый cvзләр әйтергә момкин. Без kvптән тvгел Урманлы урамы турында язган идек, әле урамында матурлык тудыручы һәм туган ягында яшәргә тагы да әйбәт булсын дип тырышучыларны kvрәбез. Коз коне булуга карамастан, голләре-чәчәкләре тирә-якны ямьләндерә. Бар жирдә тәртип урнашкан. Мәсәлән, Октябрь урамы буйлап vткәндә, ирексездән машина тәрәзәсен ачып матурлыкны хозурлыйсын. Тиз иттереп vтеп булмый булдырылган матурлык тирәсеннән. Рәсемдәге Ильдар Хәйдәр улы Васькиннын ое. Чынлап бәхет кошы кунган йортына!

Коймадан kvренеп торган агачларга, тирә-якка ямьлелек беркәп, ап-ак челән-аистлар килеп утырган, әйтерсен әле генә очып кунганнар. Бакчадан тагы башка хайваннар cvрәтләре kvренә; могжизага тин матурлык. Голләр белән бергә бер композицияне ой хужалары vзләре булдырган.
Агымдагы елнын жәй айларында (гадәткә кергәнчә ярыш һәр ел vткәрелә) Рузаевка шәһәрендә ой алдылары, оешмаларнын тирә-ягын архитектура ягыннан матур һәм яшәv очен унайлы итv конкурсы vтте. Бу конкурска ташландык материалдан vз куллары белән эшләп ой алларына, мәгариф оешмалары тирәләренә ямь остәгәннәрне дә билгеләделәр. Бу ярыш халыкка

яшәv очен матур шартлар тудыра. Дәлил иттереп рәсемдә kvрсәтелгән Ленин урамы алтмышынчы йортны алырга була.
Иске Темникта да матур яшәргә теләvчеләр kvп. Үзәк урамнын чиста йортлары чәчәккә kvмелгән. Район халкына vрнәк буларак, йорт-жир тирәләрен бигърәк матур тоталар!

Ижади якын килеп матурлык тудыручы томән халкы kvп торле әкият сыннарын vз куллары белән ясап бакчаларын бизәгәннәр. Чәчәккә kvмелеп утыручы ишек алдылары kvнелләрне kvтәреп жибәрә.
Нәкъ Иске Шәһәрдә 400гә якын кеше яши, аларнын 175 - пенсионерлар, 178 - әшче халык һәм 51 - яшьләр. Тирә-якны чиста һәм ямьле итv vрнәген дачачы Саровчылар kvрсәтә. Нәкъ алар vзенен экзотик vсемлекләре белән дан казанганнар. Авыл нинди чыгымнарга яши дигәч, Искешәһәр авылы администрациясе житәкчесе М. Н. Долбилин: «Администрация башкара торган әшләргә бvлеп бирелә торган vз доходларыбыз бик кечкенә - земельный һәм имущественный налоглар, НДФЛ һәм район бюджетыннан бирелгән дотацияләр. Шул кечкенә акчага булса да урамнарны тоне буе 31 урам фонаре яктырта, vткән ел 500 метр юл Борисовка һәм башка урамнарга салдык. Бар әштә инвестор Ю.П.Малахаевыбыз ярдәм итә. Анын сарыклар фермасы

бар. Югарыда санап киткән әшләрне башкарырга һәм чvп чыгартырга булышты һәм халыкка әш урыннары булдырды.
Бvген социаль кирәкләргә катастрофически финанслау житми. Шуна туристик юнәлеш остендә тырышып әшлибез. Тарихи яктан Темник жире бик тә истәлекле.
Старогород жире биредә туып vскәннәрне тарта, - ижади һәм хужалык әшләрен яратучыларны, авылларын vстерегә, матур итәргә теләvче кешеләрне. Зур ометләр рәссам һәм язучы якташыбыз Е.М.Тенишевага баглыйбыз. Кабатланмас шедеврларын нәкъ туган жирендә тудыра! Анын йорты тирәсеннән тыныч кына vтеп китеп булмый; һәрвакыт туктап матурлыкны хозурлыйсын. Ул ачык kvк йозе астында vз куллары һәм фантазиясе белән әкият персонажлары музее булдырган. Тагы Россиядә һәм чит илләрдә билгеле булган рәсемнәрен туган Иске Шәһәрендәге kvргәзмәдә карап булачак.

Мордовия Республикабыз Главасы В. Д. Волков яна мәдәният һәм вакытны kvнелле vткәрv Ysәге булдыруда ярдәм итәргә ышандырды. Kvптән тvгел яшь белгеч Ysәгебезне житәкли; башлады шулай булгач, кая яшь-шунда омет, шунда vсеш, дибез. Бу - актуаль». Бәхет кошлары сезнен дә оегезгә кунсын...

Наилә Насырова